| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ — КАРАР

22.12.2025 года — № 12

с. Большие Тиганы

Җирлек Советы депутатының
вәкаләтләрен вакытыннан
алда туктату турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасына нигезләнеп, Зур Тигәнәле авыл җирлеге Уставының 46 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасына таянып, М. А. Гатинның үз теләге белән отставкага китү турында язма гаризасы нигезендә,

Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2 нче сайлау округы буенча бишенче чакырылыш Зур Тигәнәле авыл җирлеге депутаты Гатин Марсель Әсхәт улының үз теләге белән отставкага китүе сәбәпле вәкаләтләре 2025 елның 22 декабреннән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.
2. Әлеге карар аңа имза салынган вакыттан үз көченә керә һәм җирлекнең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасындагы мәгълүмат стендында урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Зур Тигәнәле авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары,
7 нче сайлау округы буенча депутат — И. Ш. Хәмәтшин

СОВЕТ БОЛЬШЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ